**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23нчейорт Лаеш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 26 марты 412 номер

## КАРАР

**«Балигъ булмаганның акчалата кертемен аның законлы вәкиле алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 14 декабрендәге 272 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Гаилә кодексы нигезендә 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (19.12.2022 редакциясендә), «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм**:

1. “Баланы (балаларны) матди карап торуга акчаларны опекунга яисә попечительгә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында, шулай ук түләүле вазыйфаларын башкаручы опекуннарга яисә попечительләргә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүне түләү турында” Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 14 декабрендәге 272 номерлы карарын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А. Г. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**